ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.12.2021**

г.Зеленодольск

**КАРАР**
**№ 3084**

2021 елның IV кварталына салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендә «2021 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 699/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның IV кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 078 812 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 2 157 624 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 3 236 436 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 4 315 248 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 5 394 060 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 6 472 872 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 7 551 684 сум.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 19 095,22 сум;
1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 19 095,22 сум;
1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 19 095,22сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru)

һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев